**Д.Х.Хөснетдинов**

**Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан**

# ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНДА ҺӘМ ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРДӘ МАТДИ ҺӘМ РУХИ МӘДӘНИЯТНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ (“КОШ” КОНЦЕПТЫ МИСАЛЫНДА)

(Тикшеренүләр *11-14-1602а/В* (РГНФ) номерлы грант кысаларында башкарылды)

Данная работа посвящена отражению духовной и материальной культуры в произведениях народного творчества и художественной литературы (на примере концепта “кош”)

This article is devoted to the study of the lingo-cultural lexeme «Птица» (Bird) in the fiction, set expressions and proverbs.

**Ключевые слова**: концепт, лексема, кош.

Телнең фразеологик берәмлекләре фонды – халыкның мәдәнияте һәм менталитеты турындагы мәгълүматларның кыймматле чыганагы, аларда халыкның гореф-гадәтләр, йолалар һәм әхлак турындагы күзаллаулары тупланган. “Кош” концепты дөнья тел күренешенең төп мәдәният концептларыннан берсе – “кеше” концепты белән бәйле. Фразеологик гыйбарәләрдә “кош” концепты күп очракта кешене, аның нинди дә булса сыйфатын, холкын, уңай һәм тискәре якларын билгели.

Составында *кош* сүзе булган фразеологизмнардан иң еш очрый торганы – *кош тоткандай* әйтелмәсе. Ул юк кына табышка, я сатып алган товарга, я шундый кечкенә шатлыкка зур итеп куануга карата көлеп әйтелә. *Сиринә Самуиловнага ни булган соң, нигә кош тоткандай йөри әле ул? (З.Хөснияр).*

Алтын кош тоткан кебек дип нәрсәгә дә булса чамасыз куану, зур бәхеткә санап җилкенүне әйтәләр. Ә алтын кош – татар әкиятләрендә батырның зур каршылыкларны җиңеп чыккач кына таба, кулга төшерә алган бәхет кошы; мифик кош. Бәхет кошы да нәкъ шул ук мәгънәне белдерә. "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә бәхет кошы бәхет чыганагы һәм бәхет билгесе, символы дип күрсәтелә. *Ах, хыял түгел, әллә бәхет кошым*

*сайрыймы, ходаем? (М.Фәйзи).* Бәхет кошын кайбер язучылар кемгәдер куаныч китерәчәк, бәхетле итәчәк кешене белдерергә кирәк булганда да кулланалар. *Имеш, шагыйрьгә, буй җитмәслек йолдызга үрелеп, кысыр хәсрәттән саргаеп кипкәнче, әнә – янында бәхет кошың, шуны эләктер, дип әйтәсе килүе аның (Ф.Сафин).* Әкиятләрдән һәм элекке ышанулардан чыгып бу кош бәхетле кешенең башына үзе куна, ягъни бәхет кешенең үзеннән генә килми, аны очраклы һәм капризлы әйбер, дип уйлаганнар. Шуның нәтиҗәсендә *(башка) бәхет кошы куну* сүзтезмәсе барлыкка килгән. Ул бәхеткә, байлыкка ирешүне аңлата. Ә менә *бәхет кошын кулдан ычкындыру* киресенчә, кадерен белмәү, саклый белмәү аркасында килгән бәхетне югалту. - *Их, җүләр мин! Бәхет кошын кулдан ычкындырдым.* Бәхет кошы белән бердәй мәгънәдә кулланылучы дәүләт кошы, *(башка) дәүләт кошы* куну фразеологизмнары да бар. *Дәүләт кошы башына кунган – байлыкка ирешкән ул. Авыз(ы) белән кош тота* әйтелмәсе дә бик кызыклы. Ул телгә осталык белән кулына аулый дигән мәгънәне белдерә. Җитез, тапкыр, үткен телле кешегә карата әйтелә. *Авызың белән кош тота алмыйсың хәзер (М.Әмир).* Татар әдәбиятында *авызда кош сайрата, авызыннан кошлар очыра* дигән мисаллар да табарга мөмкин: *Дөрес, анысы, гомерем буе җебегәннәрне җенем сөймәде, әмма үзем авызда кош сайрата торганнардан түгел идем...(Г.Әпсәләмов). Авызы белән кош кына тотмый, авызында кош уйната* шулай ук оста, матур сөйләүне күрсәтә. Теле (белән) кош тота варианты бераз ирония белән әйтелә. Татар теленең фразеологик сүзлегендә аның ике мәгънәсе бирелгән: 1) үткен, авторитетлы, сүзе үтемле булу аркасында тормышы алда барган кешегә ишарә; 2) бушка сөйли, бушны сөйли, мактана.

Ала карга, саескан кебек сайрый да, җырлый да белмәүче ала кошларга охшатып затсыз кешене *ала кош* диләр: *Ала кошларга бакмакчы газизем, булма такмакчы, матур гөлләргә бул былбыл, нәзакәт багына бакчы (Дәрдмәнд).*

Ахирәт кошы – үләр вакытлары җиткән, бик картайган, бетеренгән, теге дөньяга китәсе кеше. *Ул бәлеш козгынын, ахирәт кошын... кирәген биреп чыгарырбыз (Ш. Усманов).*

*Сәдака кошы* фразеологик әйтелмәсендә “кош” концепты кешедән хәер-садака, ришвәт алу хисабына яшәүчене күз алдында тота. *Садака кошы дип таныймыни соң ул мине? (Б.Камалов).*

Фразеологизмнар составында “кош” концепты кешенең тышкы кыяфәтен дә тасвирларга мөмкин. Мәсәлән, ипсез-шыксыз зур буйлы кешене *дөя кошы* диләр.

“Кош” концепты берүк фразеологик әйтелмәдә берничә мәгънә төсмерен белдерә ала. Мәсәлән, асыл кош берничә мәгънәгә ия: 1) затлы, кадерле саналган матур сайрый торган кош. Бу очракта ул туры мәгънәсендә була; 2) бик җете бизәнгән, төзәнгән, үзен күрсәтергә тырышкан җиңел холыклы кызларга карата көлеп әйтелә: *Менә синең шикелле егетләр шул асыл кошларны эләктерергә бакчага чыгалар (Г.Камал).* Татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән аермалы буларак, фразеологик сүзлектә әлеге концептның кадерле, өстен, югары затны белдерүе күрсәтелгән. Чыннан да, *асыл кош* сүзтезмәсе кызыклы. Экспрессив-эмоциональ бизәкләргә һәм нинди тон, нинди интонация белән әйтелүенә карап, ул уңай мөнәсәбәтне дә, тискәре мөнәсәбәтне дә белдерә ала: *Әһ-һә! Асыл кош! Каптыңмы килеп! (Г.Бәширов).* Шунысын да әйтергә кирәк: әлеге сүзтезмә хатын-кызларга гына карата түгел, ир-атларга карата да кулланыла.

*Оҗмах кошы (кошлары)* сүзтезмәсе дә игътибарга лаек. Биредә шулай ук кош концепты берничә мәгънәгә ия: 1. Чыпчыклар отрядыннан җылы якларда яши торган һәм бик матур ялтыравыклы йоннары, каурыйлары белән аерылып торган кошлар семьялыгы; русчасы: райские птицы: *Таш пулатлар керми минем, төшләремә, кызыктырмый алтын сарай, оҗмах кошы... (З.Мансур).* 2. Күчерелмә мәгънәдә сабый баланы аңлата. Гөнаһсы юк, үлсә дә җаны турыдан-туры оҗмахка китә дигән ышанудан:

*Без оҗмах кошлары булдык бу җирдә,*

*Бөтен бүлмә тулып китте савапка (Г. Тукай).*

3. Әдәби әсәрләр укыганда *оҗмах кош*ының сүзлекләрдә бирелмәгән мәгънәдә кулланылу очрагына да тап булдык. Үтә бер катлы, нәрсә әйтсәң, шуңа ышана торган, дөньядан хәбәрсез булган кеше:

*Сәгыйть кызларга ым кагып алды:*

– *Болары оҗмах кошлары инде* (Ф.Сафин, 90). Биредә кош концепты чибәр, сылу кызларны белдерә. Автор аларны оҗмахтагы хур кызлары белән тиңләп шулай атагандыр, мөгаен.

Гомумән, хатын-кызны кош белән тиңләү элек тә булган. Мәсәлән, *кош ату әйтелмәсен* карыйк. Ул, бакчада буш йөргән хатын-кызлардан берсен кулга, тозакка төшерү дигәнне аңлаткан. *Нихәл егет? Кош атарга чыктык дисеңме? Монда алар җитәрлек. Ат, егет, ат, ләкин кара, тизрәк үзеңне атып куймасыннар!*

*Тәти кош* дип әйткәндә исә буй җиткән, дәрт кергән кыз-кыркын күз уңында тотыла. *Узган ел яхшы гына тәти кошлар тозакка эләккәннәр иде (Г.Камал).* “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә *тәти кош* гади сөйләмдә кимсетеп әйтү дип күрсәтелгән.

Төн кошында да кош концепты берничә мәгънәдә кулланыла: 1. Төнлә генә йори торган имезүче хайван (ярканат): *Тәрәзә яктысыннан тавышсыз-тынсыз төн кошы – ярканат атылып китә (Г.Бәширов).* 2. Төнлә йокламый йөри торган кеше турында: *Гафи – төн кошының да борыны сизгән, шикләнүе бөтенләй үк нигезсез булмаган (Ф.Хөсни).* 3. Кеше күзенә күренмәс өчен, төнлә качып-посып йөри торган кеше, төнге юлбасар: *Мин төн кошы. Алай гына да түгел, мин минут саен куркыныч астында куылып йөри торган ерткыч җанвар хәлендә (Ш.Камал).*

*Күңел кошын аулау* – сөйгән, яраткан кешеңнең күңелен табу, хисен үзеңә карату: – *Һай, сөйгән ярның күңел кошын аулау – нечкә эш.*

Кош сүзе белән бәйле диалекталь фразеологик әйтелмәләр, ягъни билгеле бер сөйләшләрдә генә кулланыла торан әйтелмәләр дә очрый. Мәсәлән, Мәләкәс якларында булдыксыз, юньсез кешене *ата кош* дип атыйлар. *Әй ата кош, шуны да аңламыйсыңмы?*

“Кош” коцепты булган фразеологизмнар арасында синоним итеп санарлыклары да бар. Мәсәлән, *дүрт стена* кошы дип өйгә бикләнеп яшәүче кешене атыйлар. – *Разия хәзер дүрт стена кошы булып яши. Атасы беркая чыгармый.* Шулай ук өйдән беркая да чыкмаучыга *йорт кошы* дип тә әйтәләр

әле: *Йорт кошы инде ул хәзер. Вакыты күбәйде. Шуңа күрә атаңның җилкәсен игәүләргә мөмкинлеге артты (Р.Хәмидуллин)*.

Димәк, фразеологик гыйбарәләрдә кош концепты күп очракта кешене, аның нинди дә булса сыйфатын, холкын, уңай һәм тискәре якларын белдерә.

Кош сүзе кергән татар халык мәкальләрендә кош кеше белән тиңләштерелә. Мәсәлән, *Кошның кошы бала өчен капкынга эләгә. Кош сайравыннан билгеле — кеше эшеннән, сөйләменнән күренә. Кош һавада сынала - кеше эшендә беленә.*

*Бала кош* лексемасының баланы белдерүен аңлау читен түгел: *Бала кош очар, кунар агачым тапмас. Бала кош очарын белер, кунарын белмәс. Бала кошның авызы зур булыр.*

Мәкальләрдә *балалар* һәм *кош* лексемалары бергә килгәндә, сабыйларын караучы ана күз алдында тотыла. Әлбәттә әти кеше дә баласын карый, аны тәрбияли. Ләкин элекке заманнарда татар гаиләсендә ана, икътисади бәйле булып, иерархик буйсыну хәлендә яшәгән, ул гаиләдә йорт хуҗалыгын алып барырга, балаларны карап, тәрбияләп үстерергә тиеш булган, һәм бу яктан ул гаять мөһим эш башкарган: *Балалы коштан җим артмый.*

Әйтеп үтелгән мисаллардан күренгәнчә, татар телендә кош компоненты кергән фразеологик берәмлекләр, сурәтләү чаралары, мәкальләр күп. Бу сүзнең кулланылу ешлыгы, лексик-семантик вариантлары булу, аның татар дөнья тел күренешендә билгеле бер урын алып торуын раслый.

Әдәбият

1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге / Г.Х.Әхәтов. - Казан: Татар.кит.нәшр., 1982.

2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. II том. Казан, Тат. кит. нәшр., 1979.

3. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. - Казан: Тат. кит. нәшр., 1987.